**1985 - 2009 еллар.**

1984 - 1985 елларда мәктәп коллективы яңа укытучылар белән тупланды.

1984 елда тарих фәненнән Рашитов Илсон, рус теле һәм әдәбиятыннан Рашитова Ф.Х., география фәнен Исламова Р.Ю., башлангыч классларда Шарипова Ф.С., татар теле һәм әдәбиятын Закирова Р. укытырга килделәр. Яшь укытучылар коллективына яңа сулыш өрделәр, мәктәпнең тормышын җанландырдылар.

1985 нче елда Рашитов Илсон җитәкчелегендә Кадыбаш мәктәбе базасында авыл тарихи музее ачылды, укучылар тарафыннан 3000 экспонат җыелды. Музей оештыру эшендә актив катнашкан укучыларны колхоз идарәсе туристик путевка белән бүләкләде. 15 укучы Рашитов И. җитәкчелегендә Мәскәүгә һәм Белорусиянең күп кенә шәһәрләренә сәяхәт кылдылар.



Тимеркаев Фәһем Мулләхмәтович

1985 елда урта мәктәпне оештыруда, мәктәпнең яңа бинасын төзүгә үзеннән зур өлеш керткән мәктәп директоры Сафин И.С. Бөгелмә шәһәренә китү сәбәпле, мәктәпкә яңа директор Тимеркаев Фәһем билгеләнде. Яшь җитәкче белем һәм тәрбия эшен җанландыру өчен күп кенә чаралар үткәрде.

1988 нче елдан мәктәпне бетерү белән лаборант булып, Шайхутдинова Д.К. эшли башлады, 3 ел эшләгәч, Арча педагогия училищесына укырга китте, 2 ел тәрбияче һөнәрен үзләштереп, янә Кадыбаш мәктәбендә секретарь булып эшләвен дәвам итте.

1989 елда мәктәпкә яшь белгеч физика укытырга Гиззатуллина А.Ш. кайтты. Беренче тапкыр информатика фәне укытыла башлады.

Бу фән укучыларда зур кызыксыну уятты. Мәктәпкә мәгариф министырлыгы тарафыннан 10 компьютер кайтартылды.1992 елда мәктәп җитәкчелеге алыштырылды, җитәкче итеп күп еллар директор урынбасары булып эшләгән Тухватуллина Н.Г. билгеләнде. Директор урынбасары вазифаларын математика фәне укытучысы Шаймарданова К.М. йөкләнде. Яңа җитәкчеләр үз эшләрен җаваплылык белән башкардылар.

1990 елда мәктәпкә яңа укытучы Нуриева Ф.М. килде. Аңа тарих фәнен укыту йөкләнде. Мәктәп музее базасын тупландыру буенча зур эш башкарды. Аның җитәкчелегендә музей Мәгариф министрлыгы тарафыннан грамота белән бүләкләнде, музейның таныклыгы барлыкка килде. Районда иң актив эшләүче музейга әверелде.

1992 нче елда мәктәбебез укучылары Минзәлә педагогия училищесен тәмамлап туган мәктәпләренә укытырга кайттылар. Шайхутдинова Алсу Котдусовна - башлангыч, ә Заляев Илназ Нургаязович технология, физкультура укытырга билгеләнде. 1994 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаган, яшь укытучы Айдарова Земфира Раисовна математика укытырга кайтты. Аны 5 нче класска класс җитәкчесе итеп тә куйдылар.

1995 нче елның декабреннән мәктәп директоры итеп, энергияле җитәкче Рашитова Ф.Х. билгеләнде. Админстрация командысында УЭ буенча директор урынбасары Шаймарданова Кадрия Минимуловна, ТЭ буена директор урынбасары Фатхиева Дания Касимовна белән мәктәпнең бөтен тормышына яңа сулыш өрелде.

Яңа җитәкче иң беренче мәктәп бинасын чистарту, пөхтәлекне саклау өчен көрәш башлады. Салкын бинада уку мөмкин булмаганлыктан бөтен системаны үзгәртү зарур иде. Технология укытучысы Заляев Илназ Нургаязович мәктәпне электр белән җылытуга күчерде.

1995 нче елның 1 нче сентябреннән яшь укытучы Расулева Эльмира Раисовна Мөфтиева Фәния урынына 2 нче сыйныф укытучысы итеп билгеләнде. Эльмира Раисовна Арча педагогия училищесын тәмамлап, Алабуга дәүләт педагогия институтының татар теле факультетында читтән торып укыганлыктан, 7 нче сыйныфларда татар теле һәм

әдәбиятын укытырга да билгеләнде. Зур сыйныфларда хореография түгәрәкләрен алып барды. Яшь укытучы мәктәпнең 50% укучысын биюгә тартты.

1996 нчы елны Закирова Гөлия Назиповна 3 нче классларны укытырга алынды.

Техник хезмәткәрләр булып Галиуллина Роза, Башарова Зөлфия, Айдарова Флүсә, Башарова Гөлфидә, Башарова Мәрхәбәләр эшләде.

1998 нче елда мәктәпкә Кадыбаш авылына килен булып төшкән Айдарова Лилия Разиновна эшкә килде. Югары белемле математик экономика, тарих фәннәрен укытучы итеп билгеләнде. Ә инде 1 ел декрет ялыннан килгәч, химия-биология фәннәрен укытырга алынды. Бу вакытта Даутова Фәһимә апа ялга китте.

2000 нче елны Расулева Эльмира Рәис кызы институтны тәмамлады һәм Фатхиева Дания Касыймовна урынына тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп билгеләнде. 2 ел эшләгәннән соң Шаймарданова Кәдрия Миңнемулловна урынына укыту һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп куелды.

2001 нче елда Минзәлә педучилищесын тәмамлап, Исәнбай кызы Яллалова Айгөл Расимовна башлангыч сыйныфларны укытырга килде, Фатхиева Дилүсә Киамилева башлангыч класс укытучысы булып күчте.

2002 елда Чаллы дәүләт педагогия институтын тәмамлап, география белгечлеге алып, яшь укытучы Закиров Шамил Мирзиянович эшкә кайтты.

2003 нче елда Минзәлә педучилищесын тәмамлап, Бакирова Рания Заһитовна башлангыч класс укытырга кайтты.

Заманалар үзгәрде, авылларны газлаштыру программалары төзелде. 2004 нче елдан мәктәп тә газ белән җылытуга күчерелде.

2005 елда Минзәлә педколледжын тәмамлап, немец теле укытырга Габбасова Гөлназ Нагимовна эшкә кайтты. Аңа кадәр 3 ел немец теле укыткан Көчек кызы Зиннатуллина Гөлназ Рафисовна мәктәптән китте.

Мәктәптә ЕГЭ системасы 2005 нче елдан башланды. Ул вакытта Ситдиков Илшат, Закиров Булат математикадан үзләре сайлап ЕГЭ бирде һәм районда иң яхшы күрсәткечкә ирештеләр (укытучылары Шаймарданова К.М.).

2006 нчы елда Кадыбаш балалар бакчасы мәктәпкә күчерелде. Бер түбә астында бер мәгариф учреждениесе булып эшли башладылар.

Мәктәпнең укыту һәм тәрбия эшчәнлеге тамырдан үзгәрде. Мәктәп яны тәҗрибә участогында эш елдан-ел җанланды. Нәтиҗәсе дә сөендерерлек: ел саен район күләмендә җиңү яуладык, яисә призер булдык.

2006 нчы елда технология укытучысы Заляев И.Н. “Татарстанның атказанган укытучысы” исеменә лаек булды .

2007 нче елда 5 егетнең 4-се рус теле, математикадан ЕГЭ бирде: Гайсин Илнур, Гатауллин Алмаз, Нуриев Камил, Рашитов Илнур. Бу егетләр беренче тапкыр шул нәтиҗәләр белән ВУЗларга кереп, аларны уңышлы гына тәмамладылар.

2009 нчы елдан ЕГЭ штатлы режимга күчте. 3 кызның берсе-Дулкарнаева Рәмзилә ЕГЭ нәтиҗәләре белән ВУЗга керде.

2008 нче елдан фил, керпе, гөмбәләр кебек күләмле фигуралар үстереп, районда танылдык. Без үстергән фигуралар әле күп еллар Әгерҗе урамнарын да бизәп тордылар.